# Контрольно - измерительные материалы для проведения промежуточной аттестации (тестирование) по родному языку (татарскому) (для изучающих татарский язык как родной) 9 класс

## Спецификация

**1. Назначение работы**

Контрольно – измерительные материалы предназначены для проведения процедуры промежуточной аттестации учащихся 9 класса по учебному предмету « Родной язык (татарский)».

Контрольно-измерительные материалы составлены на основе Федерального компонента государственного образовательного стандарта основного общего образования, в соответствии с действующей рабочей программой по учебному предмету «Родной язык (татарский)».

**Цель:** оценка общеобразовательной подготовки обучающихся по родному языку (татарскому) за курс 9 класса.

Форма проведения промежуточной аттестации – контрольный тест.

Итоговая работа по родному языку (татарскому) за курс 9 класса в форме контрольного теста соответствует учебной программе.

Итоговый контрольный тест рассчитан на 45 минут. В ходе его выполнения ученик должен будет продемонстрировать уровень
сформированности личностных, предметных и метапредметных результатов.

**Предметные результаты**

**«Лексика»:**

- знать лексические единицы, уметь подбирать примеры лексических единиц и давать их точное определение;

**«Синтаксис»:**

- умение применять правила постановки знаков препинания в конце предложения, в простом и в сложном предложениях; определять вид связи в словосочетаниях, различать односоставные и двусоставные предложения;

**«Пунктуация»:**

- умение соблюдать пунктуационные нормы в процессе письма;
- умение находить в предложениях смысловые отрезки, которые необходимо выделить знаками препинания,
- обосновывать выбор знаков препинания и расставлять их в соответствии с изученными правилами.

**«Орфоэпия. Орфография. Морфология»:**
- умение расставлять ударения в словах;
- умение записывать слова, осуществлять самоконтроль в процессе письма, владеть навыками правописания;
- умение находить и исправлять ошибки в образовании формы слова.

**Личностные результаты:**
- готовность и способность обучающихся к саморазвитию и самообразованию на основе мотивации к обучению и познанию;
- сформированность ответственного отношения к учению; уважительного отношения к труду, наличие опыта участия в социально значимом труде;
- сформированность целостного мировоззрения, соответствующего современному уровню развития науки и общественной практики, учитывающего социальное, культурное, языковое, духовное многообразие современного мира.

**Метапредметные результаты:**
- способность и готовность ученика к освоению знаний, их самостоятельному выполнению, переносу и интеграции;
- способность к самоорганизации, саморегуляции и самоконтролю в процессе письма;
- умение находить, в том числе из предложенных вариантов, условия для выполнения учебной и познавательной задачи;
-умение находить в тексте требуемую информацию (в соответствии с целями своей деятельности).

## 2. Кодификатор контрольно - измерительных материалов

| № | Содержание проверочных заданий | Планируемые результаты | Максимал. балл |
|---|---|---|---|
| А1 | Прямая и косвенная речь | | 1 |
| А2 | Прямая и косвенная речь | **предметные:** проверить полученные знания и умения | 1 |
| А3 | Сложносочиненное предложение | | 1 |
| А4 | Вид придаточного предложения по способу присоединения | **коммуникативные:** умение размышлять и формулировать | 1 |
| А5 | Сложноподчиненное предложение с | | 1 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | синтетическим придаточным | **регулятивные:** умение достигать поставленной цели | |
| А6 | Сложноподчиненное предложение с аналитическим придаточным | | 1 |
| А7 | Виды придаточных предложений | **познавательные:** использование приобретенных знаний | 1 |
| А8 | Виды придаточных предложений | | 1 |
| А9 | Пунктуация. Знаки препинания при однородных членах | **личностные:** понимание своих возможностей | 1 |
| А10 | Пунктуация. Знаки препинания в сложноподчиненном предложении | | 1 |
| В1. | Вид придаточного предложения по значению | | 2 |
| В2. | Вид придаточного предложения по способу присоединения | | 2 |
| В3. | Главное предложение в сложноподчиненном предложении | | 2 |
| В4 | Сложноподчиненное предложение с придаточным времени | | 2 |
| В5 | Простое предложение | | 2 |

## 3. Критерии оценивания:

| Балл | 17-20 балл | 13-16 балл | 9 -12 балл | 0- 8 балл |
|---|---|---|---|---|
| % | 90-100 % | 70-89% | 45 -6 9% | 20-44% |
| Билге | “5” | “4” | “3” | “2” |

**Тест**

**I вариант**

**1 нче өлеше (А)**

**А1.** Үзгәртелеп кулланылган сөйләм ничек атала?

1) чит сөйләм;
2) автор сөйләме;
3) кыек сөйләм;
4) туры сөйләм.

**А2.** Түбәндәге схемага туры килгән рәтне билгеләргә. "Т!"- а.

1) «Сез мине җибәрәсезме7»- дип сорады Койтым бикә;
2) «Чана дисәң дә чана бу!»- диде ул;
3) «Юк минем таләбем», - диде лейтенант Майнагашев;
4) «Кем булсын инде?- диде Мәхмүт. - Шәйхулла бабай эше генә бу».

**А3.** Бирелгән җөмләләр арасыннан тезмә кушма җөмләне күрсәтегез**.**

1) Мин шулай аптырап торганда, кармагым төпкә чумды.
2) Апрель ахырларында җир кипте.
3)Фәрит кечкенә капканы ачты, алар канат белән себергәндәй чиста ишегалдына керделәр.
4) Крестьян хезмәте җиргә, табигатькә бәйле булгангамы, ул һәрчак шигъриятле булып тоела.

**А4.** Төзелеше буенча иярчен җөмләләрнең ничә төре бар?

1) 1;
2) 2;
3) 3;
4) 4.

**А5**. Бәйләүче чарасы хәбәр составында торган чаралар белән бәйләнгән җөмләнең төре нинди була?

1) синтетик;
2) аналитик;
3) баш;
4) иярчен.

**А6.** Бирелгән җөмләләр арасыннан аналитик иярченле кушма җөмләне күрсәтегез.

1) Мәсьәлә яхшырак аңлашылсын өчен, мин сине бер вакыйга белән таныштырып китәм.
2) Күршеләр керсә, бик күңелле була ул кич утырулар.
3) Сандугач җырын тыңлыйм дип, үз җырыңны онытма.
4) Ул хәзер белә: зур сулы авылның халкы әйбәтрәк холыклы була.

**А7.**Иярчен җөмләнең мәгънә ягыннан төрен билгеләгез?
***Күренеп тора: бер дә тәҗрибәң юк әле синең, энем.***

1) иярчен тәмамлык;
2) иярчен ия;
3) иярчен хәбәр;
4) иярчен аергыч.

**А8.** ***Су өсте тыныч, шуңа күрә дә елтыр чабаклар башларын судан чыгарып алалар***. Әлеге җөмләнең мәгънә ягыннан төре нинди була?
1) иярчен урын;
2) иярчен сәбәп;
3) иярчен күләм;
4) иярчен максат.

**А9.** Җөмләдә билгеләнгән урында нинди тыныш билгесе куела? ***Ир, хатын, бала-чага, яше, карты < …. > һәммәсе Яманкул чокырына агылды.***
*1) куштырнак; 2)өтер; 3)җәяләр; 4) сызык*

***А10.*** Кайсы җөмләдә баш җөмлә белән иярчен җөмлә арасына өтер куелырга тиеш?

1)Бүген яңгыр яумас < …. > көн аяз, болыт әсәре юк.
2)Мин белмәгән < …. >нәрсәләр күп икән бу дөньяда.
3) Алгы тәгәрмәч кая тәгәрәсә < …. > арты да шуннан тәгәри.
4) Телең ни әйтсә < …. > колагың шуны ишетер.

**2 нче өлеше (В)**

1) Кәрим сизенә килде: кояш белән көнбагыш арасынданиндидер уртаклык, яшерен бәйләнеш бар, чөнки бакчадагы дусты кояш әйләнеше уңаена көнозын талгын гына борыла икән бит. 2) Кояш иртән кай яктан чыкса, көнбагыш шул якка караган була. 3)Кичләрен чуклы-чуклы башын кояш баешы ягына бора. 4)Көнбагышның җанлы икәнлегенә ышанды Кәрим, шуңа күрә ул аны иң якын дусты дип таныды. 5)Сентябрь җиткәч, ул беренче сыйныфка укырга барачагы хакында озаклап сөйләде. 6) Дусты аны бирелеп тыңлады. 7)Көнбагышның дәү-дәү яфраклары кулларына орынганда, Кәрим сәер пышылдау ишетә: син тиздән мәктәпкә барасың, зур үсәсең.

8) Өлкәннәргә серләреңне сөйләсәң дә, алар сине күп вакыт аңлап бетермиләр. 9)Кәрим шуңа төшенде: сөйләшер, серләшер өчен көнбагыштан да яхшы һәм ышанычлы иптәш юк, чөнки ул алдашмый, үртәшми, кояшка һәм синең күзеңә карап тора.10) Кәримнең кайчак озын буйлы көнбагышка әвереләсе, аның кебек кояш уңаена талгын гына борыласы килә. 11) Әмма тылсымлы әверелеш ясарга кулыннан килми шул аның. (Р.Низамиев)

**В1**. 2 нче җөмләнең мәгънә ягыннан төрен язарга

**В2**. 8 нче җөмләнең төзелеше ягыннан төрен билгеләгез

**В3**. 7 нче җөмләнең баш җөмләсен күрсәтегез.

**В4**. Иярчен вакыт җөмләсе булган җөмләнең номерын языгыз.

**В5**. Гади җөмләнең номерын языгыз.

**Дөрес җаваплар**

| № | Җаваплар |
|---|---|
| **А 1** | **3** |
| **А2** | **2** |
| **А3** | **3** |
| **А4** | **2** |
| **А5** | **1** |
| **А6** | **4** |
| **А7** | **2** |
| **А8** | **2** |
| **А9** | **4** |
| **А10** | **3** |
| **В1** | **урын** |
| **В2** | **синтетик** |
| **В3** | **Кәрим сәер пышылдау ишетә** |
| **В4** | **5** |
| **В5** | **6** |